КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 8 апрель г.Казань № 325

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында торучы балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары турында мәгълүматларның дөреслеге, актуальлеге һәм тулылыгы өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 5 октябрь, 949 нчы карары белән расланган Балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында торучы балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары турында мәгълүматларның дөреслеге, актуальлеге һәм тулылыгы өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында торучы балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары турында мәгълүматларның дөреслеге, актуальлеге һәм тулылыгы өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 5 октябрь, 949 нчы карары белән расланган Балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында торучы балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары турында мәгълүматларның дөреслеге, актуальлеге һәм тулылыгы өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәгә «VI. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) өчен контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның

максатчан мәгънәләре» бүлеген  түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«VII. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) өчен төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан мәгънәләре, индикатив күрсәткечләр

53. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төп күрсәткечләре:

Министрлыкка Реестрга кертү өчен үз эшчәнлеге турында дөрес, актуаль һәм тулы мәгълүмат бирмәгән контрольдәге затлар өлеше;

контрольдәге  затлар тарафыннан төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) узарга тиешле мәҗбүри таләпләрне  үтәү өлеше;

мәҗбүри таләпләрне бозучы эшчәнлекләрен тикшерү нәтиҗәләре буенча контрольдәге затлар өлеше.

54. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру эффективлыгының һәм нәтиҗәлелегенең индикатив күрсәткечләре:

1) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

4) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

5) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

7) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

8) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

9) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

15) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

16) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

18) хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

19) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

20) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.

55. Төп күрсәткечләргә анализ календарь ел йомгаклары буенча әзерләнә торган контроль (күзәтчелек) рәвеше турында докладта гамәлгә ашырыла.».

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин